МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.11.2024 Казан ш № 755

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.08.2016 №465, 14.05.2018 №363, 10.10.2018 №935, 22.01.2019 №45, 03.04.2019 №226, 05.08.2019 №595, 23.10.2019 №888, 14.07.2020 №514, 28.09.2020 №680, 08.09.2021 №645, 14.02.2022 №102, 29.08.2022 №811, 08.12.2022 №1085, 09.03.2023 №143, 20.07.2023 №587, 05.08.2024 №548 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның «12» ноябрендәге 755 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 санлы боерыгы белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша, КФҮ һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) арасында төзелгән үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда бирергә мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар КФҮ белгече тарафыннан кабул ителми.»;

2.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.»;

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү турында гариза (алга таба – гариза):

кәгазьдә әлеге Регламентка $1^1$ номерлы кушымтадагы форма буенча.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына)

интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

070/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен белешмә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары) кушымтасының 1 пунктындагы өченче абзацта һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документлар;

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта);

мөрәҗәгать итүчедә законнар нигезендә мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә (мөрәҗәгать итүчедә шундый авыру булган очракта).

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрне һәм затларны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле нигездә үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган, махсус хәрби операциядә катнаша торган гражданнарның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча тикшерү идарәсенә вазыйфага күчерү тәртибендә билгеләнгән хезмәткәрләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән, махсус хәрби операция барышында һәлак булган (үлгән) кешеләрнең гаилә әгъзалары (алга таба, тиешенчә – махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү тәртибен (алга таба – Тәртип) куллану максатларында андыйларга әлеге гражданнарның хатыны (ире) һәм ата-анасы да

керә, шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итүгә беренче чиратлы хокук булуын исбатлау өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыралар:

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән, аларны махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына яки махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслаучы документларның күчермәләре һәм нотариаль таныкланган тәрҗемәләре;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясына ярашлы рәвештә, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданинның шәхси мәгълүматларын Идарәгә (бүлеккә) тапшыру һәм эшкәртүгә ризалыгы.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче документларның төп нөсхәләрен яисә аларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләрен тапшыра.

Гаризаны мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе аша Идарәгә (бүлеккә) тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

КФҮ аша.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) яки КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.»;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәре турында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацында һәм 2 пунктындагы бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрдән тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан);

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән);

шәхси счетның иминият номеры турында( Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар

һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүчене махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына яисә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләре турында (Гражданлык хәле актларын теркәү бердәм дәүләт реестрыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсеннән);

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданинның (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә аның (махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу факты турында (махсус хәрби операциядә катнашу өчен Россия Федерациясе гражданнарын җибәргән (җәлеп иткән) федераль башкарма хакимият органнарыннан (федераль дәүләт органнарыннан), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты, Россия Федерациясе Милли гвардиясе, Татарстан Республикасы район (шәһәр) хәрби комиссариаты (алга таба – вәкаләтле органнар)).

шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булуы турында (шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булуы турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан);

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә түбәндәге белешмәләр алына:

мөрәҗәгать итүче паспортының гамәлдә булуын раслау турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.7.1 пунктының икенче абзацында «шушы Регламентның» сүзләреннән соң «, шул ук вакытта әлеге регламентның 2.6.1 пунктының унберенче абзацында

каралган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык булмау гаризаны һәм документларны кабул итүгә комачауламый» сүзләрен өстәргә;

2.13.1 пунктының алтынчы абзацында «, КФҮ аша;» сүзләрен өстәргә;

2.14.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, шулай ук Татарстан Республикасының теләсә кайсы КФҮ гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә, КФҮ һәм Министрлык арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.14.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасы» мәгълүмат системасы».

2.14.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.9. Дәүләт хезмәтен КФҮ аша күрсәткәндә консультацияне һәм документларны кабул итүне КФҮ белгече башкара.»;

Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә, гариза Идарәгә (бүлеккә) теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.»;

3 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 3.2$^{1}$ пунктын өстәргә:

«3.2$^{1}$ Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән составы, тапшырыла торган документация формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.1$^{1}$ пунктын өстәргә:

«3.3.1$^{1}$ Мөрәҗәгать итүчеләр гариза һәм документларның күчермәләрен КФҮ аша тапшыра ала.

Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮ аша, яшәү урынына бәйсез рәвештә, экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән

документларны кабул итү КФҮ эш регламенты һәм КФү белән Министрлык арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Техник мөмкинлек булганда, документларны Идарәгә (бүлеккә) КФҮ мәгълүмат системасы аша электрон рәвештә (КФҮ ЭЦИ белән имзалаган документларның скан-рәсемнәре) тапшыралар. Техник мөмкинлек булмаганда, кәгазь чыганаклардагы документлар КФҮ һәм Министрлык арасында төзелгән килешүдә күрсәтелгән ешлык белән, ләкин гариза КФҮ теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып КФҮ тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш) тора.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан);

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән);

шәхси счетның иминият номеры турында( Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәре турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмавы турында (Федераль салым хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүчене махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына яисә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләре турында (Гражданлык хәле актларын теркәү бердәм дәүләт реестрыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсеннән);

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданинның (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә аның (махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу факты турында  (вәкаләтле органнардан).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарәдә (бүлектә) ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада да, документлар һәм белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Идарәдә (бүлектә) теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Идарәнең (бүлекнең) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

күчемсез милек турында мәгълүматлар. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәре турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булуы турында белешмәләр (шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булуы турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң). Рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмавы турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

мөрәҗәгать итүчене махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына яисә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләре турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын рәсмиләштерү идарәсенә җибәрелә;

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданинның (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә аның (махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзалары өчен) махсус хәрби операциядә катнашу факты турында белешмәләр. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать вәкаләтле органнарга җибәрелә;

мөрәҗәгать итүченең паспорты гамәлдә булуын раслау турында. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә (мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә);

яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүченең теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында. Белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә (мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә).

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.9 пункт өстәргә:

«3.9. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе КФҮ Идарә (бүлек) тарафыннан ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә кую турында, ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә куюдан баш тарту турында бирелгән карардагы техник хаталарны төзәтү турында язма гариза бирә ала.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризалар әлеге Регламентның $3.3.1^1$ пунктында каралган тәртиптә кабул ителә.

Процедура нәтиҗәсе: КФҮ тарафыннан кабул ителгән, теркәлгән һәм Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән техник хаталарны төзәтү турында гариза.»;

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогын бозу;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат, КФҮ дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән,  2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.»

5.2 пунктның өченче абзацында «күпфункцияле үзәк аша» сүзләрен «КФҮ аша» сүзләренә алмаштырырга;»;

5.4 пунктның 3 һәм 4 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (учреждение

хезмәткәренең) яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

әлеге Регламентка №1[1] кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №1[1] кушымта

Рәвеш

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)
____________________________________
Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында)

Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама
белән тәэмин итүгә гариза

Мин,_______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес: _______________________________________________
__________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең индексы күрсәтелгән почта адресы, телефон, электрон адрес)
__________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)
__________________________________________________________________
ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итүгез турында, форма N070/у «__»_________20__ ел _____________.
(дата) (авыру коды)

СНИЛС (мөрәҗәгать итүченең)

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документ исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Мин гаилә әгъзасы: ата-ана, хатын (ир).
(кирәклесен ассызыкларга):
махсус хәрби операциядә катнашучы гражданин /
махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданин (кирәклесен ассызыкларга),
Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер», «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча тикшерү идарәләренә вазыйфаларга күчерү тәртибендә билгеләнгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе хезмәткәрләре исәбендәге гражданнар (кирәклесен ассызыкларга)

______________________________________________________________________,
(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы)
һәм өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшырам (махсус хәрби операциядә катнашучы гражданинның гаилә әгъзасы һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданинның гаилә әгъзасы тарафыннан гына тутырыла):

| № | Документ исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Тапшырылган белешмәләрнең һәм документларның дөреслеген раслыйм.

Мәгълүмат алу, шул исәптән ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү яисә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама бирүдән баш тарту турында, килешәм (риза).

Түбәндәгечә белдерүгә килешәм (риза):
почта адресы буенча язма формада: ______________________
______________________________________________________________________;

________________________________телефонына смс-хәбәр итеп;
әлеге электрон почта адресы буенча электрон документ формасында: ________
_________________________________________________________________________;
шәхси кабинет аша Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында: ________________________________.

Миңа шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә, шулай ук мәгълүмат бирүгә кагылышлы нинди дә булса үзгәрешләр (адресы, телефоны һ.б.) булган очракта, бу хакта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы ___________________ муниципаль районы (шәһәр округы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) хәбәр итәргә кирәклеге турында белдерелде.

___________________________________ _____________ «__» _______ 20___ел.
Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имза)

Аңа беркетелгән документлар белән гаризаны ____ нөсхә биттә белгеч кабул итте_______________________________________________________
(органнның/учреждениенең исеме күрсәтелә),
________________________________________________________________________а
ның белгече теркәлгән документлар белән гаризаны кабул итте)
Мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документтагы белешмәләр тикшерелде.
______________________________________ ____________ «__» _______ 20___ел.
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)) (имза)

________________________________ кисем сызыгы _____________________________

Язунамә

Гариза ___________________________________________ «__» _______ 20__ел.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итүгә, №070/у формасы буенча,20____ елның «__»_________, кабул итүче белгеч
(авыру коды)

__________________________________________________________________________
(белгеч гаризаны кабул иткән орган/учреждение исеме күрсәтелә)
_______________________________________ ___________ «__» ________ 20___ ел.
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)) (имза)».